РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» февраль 2024 ел г. Альметьевск № 730

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга Әлмәт муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 8 маендагы 615 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында»2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карарын гамәлгә ашыру максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2025 елларга Әлмәт муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 8 маендагы 615 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 сентябрендәге 1357 номерлы, 2021 елның 17 февралендәге 243 номерлы, 2021 елның 8 ноябрендәге 1584 номерлы, 2023 елның 24 октябрендәге 4167 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 3 пунктында «ЕГИССО» сүзен «социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» сүзләре белән алыштырырга;

1 нче кушымтаның 2 бүлегенең егерменче абзацын карарга түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа системасында торак шартларын яхшырту өчен яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм күләмнәре нигезендә, социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа операторы билгеләгән рәвешләр нигезендә урнаштыруны тәэмин итү.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

заказ № 1-851

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов